


**Таныш булыгыз менә**

**Исемем  минем –ГӨЛГЕНӘ!**

**Бар эшкә дә өлгерәм:**

**Юам, тегәм, пешерәм.**

**Әни әйтә: «Гөлгенәм,**

**Син бит минем бергенәм!»**




30/08/2009






**Ишегалдым-яшел бишек,**

**Уйнап үсәм чирәмендә.**

**Балачакның хатирәсе**

**Мәңге калыр исләремдә.**





Авылыбыз уртасында,

Балалар бакчасы бар.

Әти-әни эштә чакта,

Кала анда балалар.





Мин дә мәктәпкә барганчы,

Бакчага теләп йөрдем.

Тәрбияче апалардан

Күп һөнәрләр өйрәндем.








**Мәктәпкә шатланып барам,**

**Укыйм, язам тырышып.**

**Иптәшләрем белән бик дус,**

**Бишле алабыз узышып**





# Ә мәктәбебез ничек матур бит безнең!

# Килешәсезме?














Дəреслəр беткəч мəктəптə,

Мəдрəсəгə йөгерəм.

Дога ятлыйм, Коръəн тыңлыйм,

Барысына да өлгерəм.



**Җәйге каникулларны**

**Сагынып көтеп алабыз,**

**Балык тотып, су коенып,**

**Шәһәргә дә барабыз.**







**Диңгезнең тозлы суыннан**
**Кабырчыклар җыябыз.**
**Гаиләбез белән шулай**
**Рәхәт үтә ялыбыз.**







07/06/2009


12/07/2008

**Бер, ике, өч - бездә күмәк көч!**

**Тимераякта шуу бигрәк рәхәт ич.**

**Чыныккач шулай чирләмим бер дә**

**Спорт – сәламәтлек кушылыгыз сез дә!**



**Зур эшләр майтарып шулай,**

**Арып-талып кайтам өйгә.**

**Мунча әзер – юынырга!**

**Себерке пешкән – чабынырга!**

**Ташы кызган, пары чыга,**

**Чыдап булмый кызуга.**

**Чыгып йөгерәм урамга,**

**Кар белән уынырга.**

